РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 15 сентябре № 38

Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 бүлектәге 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1 Халык яки Түбән Кама шәһәр Советы инициативасы белән үткәрелә торган иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар шәһәр Советы тарафыннан, Түбән Кама шәһәре Мэры инициативасы буенча - Түбән Кама шәһәре Мэры тарафыннан, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча - Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.»

9 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 9.3 һәм 9.4 пунктлары белән тулыландырырга:

«9.3 Бер яки берничә торак пункт территориясенә, аларның өлешләренә карата җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар генераль планга үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелә. Бу очракта иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар үткәрү вакыты бер айдан артык була алмый.

9.4 РФ Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясындагы 7.1 өлешендә күрсәтелгән очракта, генераль планга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проект буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар үткәрү вакыты, муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә мондый иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр ителгәннән соң, мондый иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылган көнгә кадәр муниципаль берәмлек уставы һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан да кимрәк һәм ике айдан да артык була алмый.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары М.В.Камелина